**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1206**
**20.02.2021**

Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 19 гыйнварындагы 214 номерлы карары белән расланган гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Ситдыйков Салават Әнәс улын комиссия составыннан чыгарырга;

2) Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Гайнуллин Илдар Наил улын комиссия составына кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                                   Ф.Ш. Салахов